

# Шиабиев Мулланур- участник 3-х войн

Шиабиев Мулланур 1896 елда Алабуга өязе Салагыш волостендагы Бәзәкә авылында Шиһабетдин Мехамәтгалиев (1856 елгы) һәм Сәрбиҗамал Әлмехамәтова (1857 елгы) гаиләсендә туа. 1897 елгы перепись вакытында алар гаиләсендә апалары Майбәдәр (12 яшьлек), Хөсниҗамал (7 яшьлек) һәм Гыйлмиҗамал (4 яшьлек) тора (А.Х.Махмутова, «Колыбель моя, Бизяки», стр.447, п.115).




*Бәзәкә авылы шәҗәрәсе. Шиабиев Мулланурның нәселе: Мехәмәтрәхим-Мехәмәтәмин-Мехәмәтгали-Шиһабетдин-Мулланур-Багданур, Зиннур, Хаҗинур, Әхмәтнур- (Айдар Шиабиев)*

Беренче бөтендөнья сугышы башлангач Мулланур абзыйны солдат хезмәтенә алалар. Архив документларында аның турында язмалар табып булмады. Бу Мулланур абзыйның сугышны яралану/контузиясез, авыртып госпитальгә кермичә, хәбәрсез югалмыйча һәм пленга төшмичә узу бәхетенә ирешүен күрсәтә. Ә аның сугышта катнашуын С.Ф.Таҗиевның «Туган авылыбыз Бәзәкә кайда да безнең йөрәктә» китабындагы язмадан алдык (түбәндә копиясе).

> 1905-1907 елгы рус революциясенең авылга тәэсире зур булмаган. 1914 елда империалистик сугыш башлангач, авыл халкын амбар алдына җыеп, ирләрне сугышка барырга өндәгәннәр. Халык сугышка барырга теләмәгән. Шулай да авылдан сугышка китүчеләр булган. Мәсәлән, Мөхәмәтҗанов Бәхтигәрәй сугышта катнашып 1917 елгы революцияне дә сугышта каршы алган. Авылдашыбыз Фәйрушин Әхмәдиша сугышта булып яраланып кайткан. Шиабиев Мулланур да шулай ук илнең төрле почмакларында барган сугышларда катнашкан. Кәлимуллин Кирами революцияне шулай ук сугыш кырында каршылаган. Байтак авылдашлар сугыш кырында ятып калган...

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Фархизиган Мусифуллина | 42 | | | У муллы | |
| | Ахунзян | 8 | | | | |
| | Бахтигарай | 5 | | | | |
| | Фархинур | 12 | | | | |
| 114 | Шафик М-галеев | 55 | Баш | | | |
| | Хуснутдин Юсупов | 35 | г/кр | Вят/г, Елаб/у Варзиятч /в Ново-Бизяк | | вдов н/ч запаса |
| | Минизиган Хабибуллина | 25 | г/кр | | | |
| | Смагил Хуснутдинов | 8 | г/кр | | | объед. в 1 х-во |
| | Муллаахмет Хусн | 4 | г/кр | | | |
| | Минихузя Хусн | 3 | г/кр | | | |
| | Миниадия Хусн | 2мц | г/кр | | | |
| 115 | Шагабутдин М-галеев | 41 | башк | | | н/ч запаса 2 дома |
| | Сарбиямал Альмух | 40 | | | | |
| | Мулланур | 1 | | | | |
| | Майбадар | 12 | | | | |
| | Хусниямал | 7 | | | | |
| | Гилмиямал | 4 | | | | |
| 116 | Мухаметьян Идрисов | 50 | башк | | | |
| | Фатима Губайд | 49 | | | | |
| | Мухаметзакир | 25 | | | | |
| | Мингазетдин | 23 | | | | солдат на в/сл |
| | Ахмадутдин | 14 | | | | |
| | Минихузя | 11 | | | | |
| | Минифатих | 7 | | | | |
| 117 | Гимазит-н Тимирполатов | 39 | башк | | | н/ч запаса |
| | Бибифатих Фахрутд | 30 | | | | |
| | Низамутдин | 8 | | | | |
| | Шамсиниса | 3 | | | | |
| | Минисулу | 3 | | | | |
| 118 | Ибрагим Ахметьянов | 36 | башк | турки | У муллы | |
| | Бибигафифа М-валеева | 37 | | | | |
| | Ахтамьян | 2 | | | | |
| | Ахунзян | 1 | | | | |
| 119 | Калимулла Фатхуллин | 38 | башк | | | |
| | Сарбиямал А-хакимова | 25 | | | | |
| | Салимулла | 3 | | | | |
| | Фархизиган | 2мц | | | | |
| 120 | Гилфанитдин Сиразит-в | 27 | башк | | | |
| | Шамсизиган Шакирова | 25 | | | | |
| 121 | Гиляз-н Сиразитдинов | 31 | башк | | | |
| | Махубямал Ямалетд | 26 | | | | |
| | Гильман | 2 | | | | |

447

Сугыштан Мулланур абзый авылыбызга әйләнеп кайта. Озак та үтми, ул 1919 елда гражданнар сугышына кереп китә. С.Ф.Таҗиевның «Туган авылыбыз Бәзәкә кайда да безнең йөрәктә» китабында Шиабиев Мулланур абзый Вятские Поляныдан алып Себергә кадәр Колчак армиясенә каршы сугышларда катнаша дип язылган (түбәндә копиясе китерелгән). Сугыштан соң Мәхүбҗамал Дәүләтша кызына өйләнә.

пычракта йөргәннәр. Итекләрен чабатага алыштырганнар.

1918 елның мартында Бондюгта 500 кешедән торган Кама буе партизан отряды төзелгән. Тиздән ул В.М. Азин җитәкчелегендәге армия составына кергән. Шул армиянең бер группасында авылдан 250-ләп кеше катнашкан. Таҗиев Минһаҗ 1920 елда ак полякларга каршы сугышып Ижевск шәһәреннән алып Варшавага кадәр барган һәм каты яраланып өенә кайткан. Шиабиев Муллануp белән Әхмәров Шәрәфи 1919 елда Вятские Поляныдан алып Себергә кадәр Колчак армиясенә каршы сугышларда, Хасанов Ситдыйк немец оккупантларына, Деникинга, Колчакка һәм Врангельгә каршы булган каты сугышларда катнашканнар. Гайнуллин Камали Колчакка каршы сугышларда катнашып ике тапкыр авыр яраланган. Гафиятуллин Шәех Азин дивизиясе составында Колчакка каршы пулеметчы булып Вятские Поляныдан алып Курганга кадәр араны уткән. Сугыштан кайткач алар авылдашлары белән социализм төзергә керешкәннәр.

Бөек Ватан сугышы башлангач Мулланур абзыйга тагын солдат шинеле кияргә туры килә. Бондюг райвоенкоматы аны 1942 елның 15 январендә яман даны чыккан Суслонгердагы 31-нче запас бригадага җибәрә. Аннан соң кайда хезмәт иткәне турында мәгълүмәтләр табып булмады.

Бу үзе катнашкан 3-нче сугыштан да Мулланур абзый исән-имин булып авылга кайта.

Аның гаиләсендә уллары Багданур (1944 елда Бөек Ватан сугышында хәбәрсез югала), Зиннур (Бөек Ватан сугышында катнаша, исән калып авылга кайта), Хаҗинур һәм Әхмәтнур (сугыштан соң Тын Океан флотында хезмәт иткәндә тайфун вакытында батырлык күрсәтә-бу турында сайтта язма бар) була. Бәлки кызлары да булгандыр, ләкин бездә ул турыды мәгълүмәтләр юк.

1986 елның 17 мартында 90-нчы яшендә Мулланур абзый бакыйлыкка китә һәм Бәзәкә авылы зыяратында җирләнә.

**Шагабутдинов Муманур** (Мулланур)

Списки призыва и демобилизации

Тип документа: Списки призванных

Дата рождения: __.__.1896

Место призыва: Бондюжский РВК, Татарская АССР, Бондюжский р-н

Дата призыва: 15.01.1942

Воинское звание: рядовой

Выбытие из воинской части: 15.01.1942

Куда выбыл: 31 зап. бр. *(Суслонгер)*

Дата документа: 15.01.1942

Информация об архиве -

Источник информации: ВК Республики Татарстан

Фонд ист. информации: ВК Менделеевского района

Дело ист. информации: Дело № 25 (Инв. 23) С именными списками команд отправленных 1942г.Бондюжским РВК

**Шибаев Багданур, 1923 г.р.**

Рядовой

Беспартийный

Призван Бондюжским РВК 14 июля 1943г.

70 гв.полк, п/п 828

Последнее письмо в июле 1944г. *(пропал без вести)*

????? Запрос

Мать: Шибаева Махут., Бизяки

*(Из донесения Бондюжского РВК № 1651 от 13.01.1947г.)*

**Шиябиев Зиннур Муллан.     1927**

Место рождения:   с.Бизяки

Призван Бондюжским РВК  28.11. 1944

*(Сведения на граждан, призванных Бондюжским РВК Татарской АССР в годы Великой Отечественной войны 1941-1945 г.г.)*

**Шигабиев Зинур Мулагурович**

Медаль «За победу над Германией в Великой Отечественной войне 1941–1945 гг.»




Наградной документ

**Воинское звание:** красноармеец

**Воинская часть:** 235 полк КВ НКВД

**Наименование награды:** Медаль «За победу над Германией в Великой Отечественной войне 1941–1945 гг.»

Информация об архиве -

**Архив:** РГВА

**Фонд ист. информации:** 40

**Опись ист. информации:** 1

**Дело ист. информации:** 966